**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «01» декабреннән № 351

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 03 маендагы 207 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хакын тәртипкә китерү һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 207 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 290 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 233 номерлы, 2021 елның 08 ноябрендәге 438 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге 250 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) билгеләнгән тәртиптә бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдәге бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең секретаренең вазыйфаи окладының күләмен 1,061 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 12 688 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 207 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июлендәге 290 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 233 номерлы, 2021 елның 08 ноябрендәге 438 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге 250 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пункттагы 3 пунктчада «ике процент» сүзен «15 процент» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункттагы 4 пунктчада «ике процент» сүзен «15 процент»сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов